*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 40**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Хәрефләргә караганда авазлар саны күбрәк булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) төньяк
   ә) йолдыз
   б) **куян**
   в) шигырь

2. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) киттеләр
   **ә) русча**
   б) ноутбук
   в) китап

3. Диалекталь сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кишер
   ә) ассимиляция
   б) гимн
   **в) әпәй**

4. Бирелгән фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Ике күзе дүрт булу***
   а) куркудан елау
   ә) бик нык шатлану
   **б) аптыраудан шаккату**
   в) бик нык ачулану

5. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тау, тавык
   ә) төтен, төлке
   б) кала, калак
   **в) авыл, авылдаш**

6. Җөмләдәге тартым белән төрләнгән исемнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Начар кеше кеше кулы белән елан тотарга ярата*. (Мәкаль)

**а) 1**

ә) 2

б) 3

в) 4

7. Җөмләдәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

*Начар тәгәрмәч күбрәк шыгырдый*. (Мәкаль)

**а) начар**

ә) тәгәрмәч

б) күбрәк

в) шыгырдый

8. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Начар сөргән җирне чүп басар*. (Мәкаль)

а) начар

ә) җирне

**б) чүп**

в) басар

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

[ң] тартыгы сүз **башында** язылмый. **Кыскартылма** сүзләр тезмә сүзләрне кыскарту юлы белән ясала. Дәрәҗә белән төрләнә ала торган сыйфатлар **асыл** сыйфатлар дип атала. **Бүлем** саны предметларның яисә затларның тигез өлешләргә бүленүен белдерә. **Вакыт** рәвешләре эш яки хәлнең үтәлү вакытын белдерә. Татар телендә алмашлыклар **тамыр** һәм ясалма була.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

| | |
|---|---|
| *общение – аралашу* | *государство – дәүләт* |
| *душа – күңел* | *произведение – әсәр* |

2. “Минем дустым” дигән темага 8 җөмләдән торган инша языгыз. **(14 балл)**